Духовно-просветительская газета

Индекс 52381

# Төркия кунаклары изге Рамазан аен Самарада үткәрделәр

**Төркия - уникаль дәүләт. Анда бөек цивилизацияләрнең шаулап узган гаҗәеп бай тарихи сәхифәләре саклана.**

**Заманында аның бер канаты астында Европа җәелеп ятса, икенчесендә Азия илләре урнашкан булган.**

**Бүгенге көндә Ислам дине андагы хөкүмәт карамаыгында, аның сагында тора. Төркия иле үзе дә көнкүрешен Ислам дине даирәсендә алып бара.**

**Бар булган дин мәсьәләләрен хәл итү өчен анда махсус министрлык эшли. Бөтен дин әһелләре, дин галимнәре, дин гыйлемен укытучылар - барысы да тулысынча хөкүмәт карамагында. Алар хөкүмәт эшлекләре булып саналалар.**

**Төркия халкы белән төрле яктан уртаклыгыбыз бар. Болгар дәүләте, аннан соң Казан ханлыгы чорында да татарларның Төркия белән мөгаләмәләре, бәйләнеше тыгыз булган.**

**Татарлар белән төрекләр - тугандаш халыклар. Дин юнәлешенең берлеге, тел якынлыгы, тарихыбыз уртаклыгы безнең бер тамырдан булуыбызны дәлилли.**

**Бүген Төркия - югары мәдәниятле дәүләт. Анда шулай ук Ислам дине дә югары үсеш алган. Алардан күп нәрсәгә өйрәнеп, үрнәк алып эшләсәк һәм яшәсәк, безнең киләчәгебез дә, һичшиксез, уңай юнәлеш алачак.**

**Һәр елның изге Рамазан аенда Төркия иленнән Самара төбәгенә дин галимнәре килеп, халкыбызга Коръән уку тәртибен аңлатулары һәм дәресләр бирүе матур бер гадәткә әверелеп бара.**

Менә быел да Самара шәһәренә Төркиянең Ризе шәһәреннән Юнус хәзрәт Коркмаз һәм Дюздже шәһәреннән Мурат хәзрәт Өзҗан килделәр.

Без төрек кунакларыбыз белән очрашып матур әңгәмә кордык һәм түбәндә шул хакта хәбәр бирәбез.

**— Хөрмәтле кунакларыбыз, сезнең Россиягә килгәнегез бар идеме?**

— Юк, бу безнең беренче мәртәбә килүебез.

**— Бирегә килүегезнең максаты нидән гыйбарәт?**

— Безнең хөкүмәтебездә Ислам дине мәсьәләләрен хәл итүче министрлык эшләп килә. Һәр елның Рамазан аенда мөселманнар яшәгән күп илләргә безнең дин белгечләребезне махсус рәвештә җибәрәләр.

Безнең максатыбыз - халыкка Коръән укуның бөтен нечкәлекләрен, Ислам дине кагыйдәләрен, намаз уку тәртибен өйрәтү һәм барлыкка килгән төрле сорауларга җавап бирү. Гомумән, Ислам диненең асылын халыкка җиткерү.



Төркия кунаклары белән әңгәмә.

**— Беренче мәртәбә килүегез булгач, сезнең инде көчле тәэсирләр нәтиҗәсендә төрле фикерләр дә тугандыр. Шул хакта бераз сөйләп үтсәгез иде.**

— Гарәбстанда Ислам дине тарала башлаганда Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.а.с.) динсез, вәхшилеккә тарган кабиләләрне, халыкларны дин юлына бастыру өчен искиткеч зур хезмәт куйган. Үз тормышын куркыныч астына куеп, мәсхәрәүләр, җәберләүләр аша үтеп, кешеләрне вәхшилектән коткарып, дин юлына бастырган.

Сезнең җәмгыятьтәге хәлләрне күргәч, бу безгә никтер шул заманнарны хәтерләтте. Динне тиешле югарылыкка күтәрү өчен сезгә бик зур эшләр башкарасы бар әле.

**— Әйе, җитмеш елдан артык дингә каршы каты көрәш барды. Моның өстенә милләтләрне, милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне юк итүгә юнәлгән сәясәт тә зур зыян китерде. Мәчетләр җимерелде, дини гыйлем бирү системасы бөтенләй юкка чыгарылды. Гарәп илләреннән укып кайткан яшьләребез традицион Исламнан читкә тайпылалар. Алар безгә чит-ят идеология кертәләр. Бу хакта сез ни әйтер идегез?**

— Безнең бурыч - халыкка дөрес итеп Коръән, намаз уку һәм Ислам дине кагыйдәләрен өйрәтү.

Илегездәге эчке эшләргә, сәясәт мәсьәләләренә кагылу бурычы безнең алдыбызга куелмаган.

Әлбәттә, дин юлы, дин тәртибе бер юнәлештә булып, Коръән таләпләренә тәңгәл килергә тиеш.

Әгәр дә телисез икән - безгә килегез, карагыз, без һәрьяклы ярдәм күрсәтергә әзер. Безнең дин мәсьәләләре буенча министрлыкка мөрәҗәгать итсәгез, мөгаллимнәребезне, дин белгечләрен җибәреп укыту мәсьәләләрен тәртипкә сала алабыз. Эш хакын аларга Төркия дәүләте түлиячәк.

Һичшиксез, дин мәсьәләләре, укыту системасы бер юнәлештә һәм бер кулда булырга тиеш.

**— Безнең дәүләт диннән аерылган. Ислам динен алып бару төрле тармакларга бүленгән. Һәрберсенең үз лидерлары бар. Моның өстенә күпчелек дин әһелләре: «Диндә милләт юк»! - дигән катгый фикердә торалар. Милли җәмгыять оешмалары, диннән читтә буларак, үз юлларын эзлиләр. Дини оешмалар белән аларның бәйләнеше бик аз. Бу хакта ни әйтәсез?**

— Аллаһы Тәгалә кешеләрне төрле халыклар, төрле милләтләр итеп яраткан. Аларга бер-берсеннән үрнәк алып яшәргә боерган. Кеше тәрбиясенең башы гаиләгә бәйләнгән. Ата-анаңа, туганнарыңа, үз халкыңа, милләтеңә, туган илеңә карата мәхәббәт һәм тугрылык гаиләдән башлана. Кеше тәрбиясе - киң кырлы һәм катлаулы хезмәт. Аның юллары, алымнары күптөрле. Милләт - ул халыкларның зур бер гаиләсе. Анда кеше тәрбияләү мәсьәләсе, халыкның үзаңын үстерү иң алгы планда. Һәр милләтнең гасырлар буена чарланган гореф-гадәтләре бар. Алар да кеше тәрбияләүгә, җәмгыятьне үстерүгә һәм ныгытуга бәйләнгән. Болар дин карамагында бик зур көчкә ия булып, тәрбия нигезен тәшкил итәләр. Дин - ул җәмгыять бөтенлеген, халык тәрбиясен кайгыртучы гыйлем дәрьясы һәм тәрбия рәвеше.

Милләт диннән, ә дин милләттән аерым яши алмый.

Гореф-гадәтләр - милли үзенчәлекләр. Милли мәдәният, гореф-гадәтләр дин таләбенә каршы килмәгәндә генә милләт үсеше һәм халык тормышы уңай һәм бәрәкәтле була. Туган телен, үз милләтен яратмаган, якын күрмәгән кешедә үз халкына, үз иленә карата ихтирам булуы да шикле.

**— Динне халыкка җиткерү, кешеләрне дингә тарту, балаларга дини тәрбия бирү - бик тә җаваплы эш. Динне көчәйтү максаты белән бездә махсус газета чыгарыла һәм интернетта сайт эшли башлады. Аларның эшчәнлеген ничек күз алдына китерәсез? Гомумән, дини хәрәкәттә бу актуаль мәсьәләме?**

— Әлбәттә. Мәчеткә йөргән кешеләр имамнарның вәгазьләрен тыңлыйлар. Үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар табалар. Сезнең күп халык бу мөмкинлекләрдән мәхрүм, чөнки бик күпләр мәчеткә йөрми. Чын мөселман булган кеше үз туганнарын, якыннарын, күршеләрен дин юлына тартырга, аларга дини мәгълүматлар бирергә тиеш. Менә бу очракта дини информация чыганакларының әһәмияте бик зур.

Газетаның һәр санында мөфтинең, имамнарның вәгазьләре иң күренекле урында булырга тиеш. Дини дәресләр, сорау-җаваплар белән бергә тормыштагы гыйбрәтле вакыйгаларны яктыртырга кирәк. Тормыштагы уңышларга да, тискәре вакыйгаларга да дини күзлектән принципиаль бәя бирергә кирәк. Томыш - ул үзе бөек укытучы һәм тәрбияче. Газетага һәр мисалны, һәр актуаль вакыйганы аңлаешлы, кызыклы итеп, даими рәвештә биреп торырга кирәк. Дин юлында булган, аны хөрмәт иткән һәр кеше газетаны күзәтеп, аның белән тыгыз элемтәдә булып, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тиеш. Шунда гына ул файдалы, җанлы һәм кызыклы була.

Без көчле информация даирәсендә яшибез. Газетаны санламау, интернеттан читләшү - ул зур хата һәм наданлык.

**Әңгәмәне Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ алып барды.**

Объявление

**Продолжается набор детей в 4, 7 и 10 классы МБОУ СОШ «Яктылык».**

**Принимаются дети татаро-башкирской национальности.**

**Собеседование по приему детей - 24.08.2012 года в 10:00 часов.**

**Требуется воспитатель ГПД.**

**Администрация школы «Яктылык».**

**Самара татарларының сайты:**
**www.tatarlarsamara.org**

* * *

**Самара өлкә Диния нәзарәтенең һәм Самара Җәмигъ мәчетенең сайты:**
**www.islamsamara.ru**

* * *

**Тарихи мәчетнең сайты:**
**www.tarihi-mechet.ru**

***Уважаемые читатели!***

***В газете упоминаются имена Всевышнего и Его Пророка, публикуются аяты из Корана, высказывания Пророка и молитвы. Поэтому просим Вас относиться к газете уважительно, не использовать ее в недостойных целях.***

***Точка зрения авторов может не совпадать с мнением редакции.***

**УЧРЕДИТЕЛИ:** Региональное Духовное управление мусульман Самарской области и местная мусульманская религиозная организация Самарская Соборная мечеть.
**АДРЕС РЕДАКЦИИ И ИЗДАТЕЛЯ:** 443081, г. Самара, ул. Стара Загора, 54. Соборная мечеть. Телефон: 932-58-67. Электронный адрес: islam-nur@bk.ru

**Редактор** - Фарид ШИРИЯЗДАНОВ.
**Корреспондент** - Али СУЛЕЙМАНОВ.
**Ответственные за выпуск газеты:**
**по организационно-финансовым вопросам** - Джавдят ШАРАПОВ,
**по духовно-просветительской части** - Наиль СУЛЕЙМАНОВ.
**Набор и верстка** - Рамиль НУРЕТДИНОВ.
**Корректор** - Миляуша ГАЗИМОВА.

**Время подписания к печати:**

***по установленному графику - 16 августа 9.00,***

***фактически - 16 августа 9.00.***

**Отпечатано в ОАО «Типография «Солдат Отечества»**

**Адрес: г. Самара, ул. Авроры, 112 Б.**
**Заказ Тираж 2000.**

***Цена свободная.***
Рег. свидетельство
ПИ № ТУ63-00111